СОВЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

# КАРАР

2022 нче елның 29 сентябрь № 27/3

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советы 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль законга таянып карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылуда катнашу турында " 2019 елның 15 ноябрендәге 77/4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.13 пунктчасы белән тулыландырырга:
«3.13. нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирү.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктын өстәргә:
«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре күрсәтелгән 3 пунктта нотариаль гамәлләр башкарылган очракта нотариаль документларны саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм куллануны тәэмин итә. Җирлек бетерелгән яки муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, бетерелгән яки үзгәртелгән җирле үзидарә органының нотариаль документлары җирле үзидарә органына тапшырыла.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларына, Чүпрәле муниципаль районы рәсми сайтына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru).

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы: В.Г. Ранцев